**2021 елның 1 яртыеллыгында Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү турында мәгълүмат**

2021 елның 1 яртыеллыгында шәһәрнең җирле үзидарә органнарында гражданнар тарафыннан язмача җибәрелгән һәм шәхси кабул итүдә бирелгән **4504** мөрәҗәгать каралды (2020 елда – 4437).

Мөрәҗәгатьләрнең гомуми санынннан:

**2808** е – язмача мөрәҗәгать 2020 елда – 3147).

Шәһәр Хакиме һәм Башкарма комитет Җитәкчесе адресына 3966 мөрәҗәгать итүчедән 121 коллектив мөрәҗәгать керде (2020 елда – 4055 мөрәҗәгать итүчедән 91 коллектив мөрәҗәгать).

Шәһәр халкын борчыган мәсьәләләрне хәл иткән өчен, шәһәр Хакименә һәм Башкарма комитетның структур бүлекчәләренә рәхмәт җиткерелгән 20 мөрәҗәгать керде.

2808 мөрәҗәгатьнең 463 е уңай хәл ителде, бу гомуми санның 16,5% ын тәшкил итте, 79 ы ведомстволарга җибәрелде, калган мөрәҗәгатьләр буенча аңлатмалар һәм рекомендацияләр бирелде.

Үзләренең социаль хәлен күрсәткән мөрәҗәгать итүчеләр составында түбәндәге категорияле гражданнар бар:

- пенсионерлар: 197 (7,02 %);
- эшләүчеләр: 124 (4,42 %);
- эшсезләр: 56 (1,99 %);
- эшмәкәрләр: 40 (1,42 %);
- хезмәткәрләр: 34 (1,21 %);
- хуҗабикәләр: 23 (0,82 %);
- укучылар: 17 (0,61 %);
- интеллигенция: 15 (0,53 %);
- социаль хәлен күрсәтмәүчеләр: 2302 (81,98 %).

Мөрәҗәгать итүчеләр арасында үзенең льготалы категориягә ия булуын күрсәткән гражданнарның күпчелеге: инвалидлар – 90 (3,21 %), күп балалы гаиләләр – 70 (2,49 %), хәрби хәрәкәт ветераннары – 15 (0,53 %), ялгыз ата-аналар – 5 (0,18 %), Бөек Ватан сугышы ветераннары – 1 (0,04 %).

Гражданнардан кергән язмача мөрәҗәгатьләрне анализлау шуны күрсәтә, шәһәрдә яшәүчеләр өчен 2021 елның 1 яртыеллыгында түбәндәге мәсьәләләр актуальрәк саналган:

- торак-коммуналь хуҗалыгы – 964 (2020 – 806);
- төзелеш – 276; (2020 – 208);
- юл хуҗалыгы – 257 (2020 – 276);
- мәгариф һәм мәктәпкәчә тәрбия – 244 (2020 – 384);
- җирдән файдалану – 196 (2020 – 162);
- торак өлкәсе – 189 (2020 – 191);
- социаль тәэмин итү – 127 (2020 – 296);
- сәүдә һәм кулланучылар хезмәте – 92 (2020 – 118);
- транспорт хезмәте күрсәтү – 89 (2020 – 113);
- сәламәтлек саклау – 79 (2020 – 116);
- законлылык һәм хокук тәртибен тәэмин итү – 68 (2020 – 116);
- финанс өлкәсе – 49 (2020 – 47);
- хезмәт һәм мәшгульлек – 41 (2020 – 89);
- элемтә мәсьәләләре– 32 (2020 – 39).

**1696** чаллылы шәхси кабул итү вакытында кабул ителде (2020 – 1290).

586 мөрәҗәгать буенча кирәкле чара күрелде, 1080 мөрәҗәгатькә аңлатмалар бирелде, 30 мөрәҗәгать контрольдә тора.

Шәһәр Хакиме һәм Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан 148 чаллылы кабул ителде.

Җирле үзидарә органнарында гражданнардан кергән бер генә мөрәҗәгать тә игътибарсыз калмый.

Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрнең мониторингы көн саен үткәрелә, мөрәҗәгатьләрне үз вакытында карап тикшерү контрольдә тотыла, үтәү дисциплинасына анализ ясала.

Гражданнар мөрәҗәгатьләрендә бәян ителгән мәсьәләләр компетенция кысаларында оператив рәвештә хәл ителә.

Мөрәҗәгать итүче һәркемгә гамәлдәге законнар нигезендә язмача җавап һәм аңлатма бирелә.